КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 октябрь г.Казань № 1343

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Музей предметларын, музей коллекцияләрен халыкка күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 1 ноябрь, 832 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 6 сентябрь, 615 нче; 2018 ел, 9 июнь, 441 нче; 2018 ел, 4 декабрь, 1082 нче; 2020 ел, 3 август, 644 нче; 2023 ел, 16 июнь, 723 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Музей предметларын, музей коллекцияләрен халыкка күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына, 14.4 пункттагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Концертлар һәм концерт программалары күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын, Спектакльләр (театраль куелышлар) күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын, Цирк программаларын күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 ел, 25 сентябрь, 871 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 16 июнь, 723 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Концертлар һәм концерт программалары күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартында:

II бүлекнең егерменче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

14.2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Спектакльләр (театраль куелышлар) күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартында:

II бүлекнең егерме икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

14.2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Цирк программаларын күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартында:

II бүлекнең унтугызынчы абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

14.2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин